■ Дин вә гавәм

# ХАТЫН-КЫЗНЫҢ ШӘРӘЛЕГЕ...

Нияз САБИРҖАНОВ

Хатын-кызны ялангач калдыруны хуп күрүче хәзерге заман модасы Европа цивилизациясен үлеп бетүгә алып бара. Хәтта үҙ биләмәләрендә дә ул башка этнослар көндәлек тормышта өлешчә эксгибиционизмга (җенси билгеләрнең ачык белдерелүенә) тыю булганнары белән торган саен күбрәк алмыштырыла.

Җир йөзендә европалыларның урынын үз хатыннарының әхлакый сафлыгын һәм яшертенлеген саклый алган һәм шуның белән бергә шулай ук үз ир-атларын да саклый белүче халыклар алмаштыра. Беренче нәүбәттә, болар - ислам дөньясы халыклары.

Ирләрдә җенси теләк кузгатучы хатын-кызның күркәмлеген күзгә бәрелеп тора торгандай итүне “җенси тетрәнү” булдыру рәвешендә карарга мөмкин. Шуның аркасында импотенциягә һәм яман шеш авыруларына китереп җиткерүче “җенси яктан читкә кагылганлык”ның катлаулы эчке организм комплексы башлана. Бу хакта күренекле табиб, академик Л.А.Китаев-Смык үзенең “Стресс психологиясе. Стрессның психологик антропологиясе” (“Психология стресса. Психологическая антропология стресса”) дигән фундаменталь монографиясендә яза.

“Кулланылыш җәмгыяте” өстенлек иткән илләрдә соңгы дистә елда хатын-кызларның нәфислеген, фәнни тел белән әйткәндә, икенчел җенси билгеләрен басым ясап күрсәтүче һәм ялангачландыручы мода буенча тегелгән кием-салым нормага әйләнде. Хатын-кызның шәрә корсагы һәм кендеге, түбәндәрәк ни барлыгын дәлилләүче символ сыман баш катыргыч гадәтилеккә әйләнде, тәнгә сыланып торучы йомры формалар, җилбәгәй ачып җибәрелгән муен һәм күкрәк тирәсендәге зур изүләр күңел аздыра, ярсыта... Физиологик күзлектән чыгып караганда, боларның һәммәсе дә - ир-атларда көчле җенси теләк уятучы сексуаль сигнал.

Һәрбер ярсыну теләккә китерергә тиеш: табигать тарафыннан салынган механизмы шундый. Ир белән хатын арасындагы эрос - нәсел булдыру коралы, ул үзенең барлык очракларында да организмга рәхәтлек бирә һәм файдалы. Нормаль эротик аралашуның һәм уңышлы җенси мөнәсәбәтләрнең искиткеч уңай тәэсире барлыгын без яхшы беләбез. Шуңа күрә дә, аерым алганда, традицион диннәр өйләнешүне һәм ирле-хатынлы булып яшәүне хуп күрә.

Әгәр дә ярсыну еш кузгалса һәм нәтиҗәсез булса, күзаллауларга кысрыклап чыгарылып, аңлаудан туктый. Урамда, офисларда, шәһәр транспортында хатын-кызларның күркәмлегенә ир-атлар еш тап булса, алар үзләренең җенси хискә бирелү омтылышын хәтта сизүдән дә туктый. Әмма ир-егетләрнең аңына кереп урнашкан җенси ярсыну канга андроген җибәрүен дәвам иттерә, әмма инде онкологик яктан зарар-зыян китерми торган күләмдә, ә концероген дозировкада “бәхетсез аталыкны яраксызга чыгару”ның эволюцион механизмнары катнашып китә.

Шәһәр кешесе уртача алганда мондый сигналларга көнгә 100-200 тапкыр тап була. Нәтиҗәдә, еш ярсынып та, канәгатьлек алмаган ир-ат үз организмында эчтән куәтле, җимергеч, концероген һөҗүм ала һәм ул яман шеш авыруына илтеп җиткерә.

“XXI гасырның күп кенә хатыннары үзләренең ялангач аяклары һәм ачык изүләре белән ир-атларның сәламәтлегенә кабер казый. Топик киеп очрашуга барган һәрбер чибәркәй бары тик берәүне - бәхетле, ә барышлый ун ир-атны инвалид итә. Стриптиз биеп йөрүче кызларны инде, гомумән, Көнбатыш цивилизациясен чиргә сабышкан ир-атлар җәмгыятенә әверелдергән “күпләп юк итү коралы” дип санарга мөмкин”, - ди “Әссәлам” газетасы хәбәрчесе белән үткәргән әңгәмәдә Л.А.Китаев-Смык.

Шунысы кызык: хатын-кызларда “сексуаль стресс” аркасында килеп туган яман шеш авырулары ир-атларда була торганнардан үзгәрәк сыйфатларга ия. Хатын-кызлар онкологиясенең төп сәбәбе (күкрәк бизләрендәге аналык һәм күкәйлекләрдәге зарарсыз һәм яман шешләр) - җенси аралашу (сексуаль актлар) белән шөгыльләнеп тә, бала тапмау һәм имчәк баласын имезмәү белән бәйле. Хатын-кызларның катлаулы, эчке организмнарындагы структуралар бала тапмауларының һәм имезмәүләренең нәсел калдыруга сәләтсез икәнлекләренә сигнал буларак кабул ителә. Имеш. әлеге структура - гаиләдә, этнос өлкәсендә ир-атларның сексуаль потенциалын файдасызга читләштерүче кирәксез артык йөк. Биологик эволюция тарафыннан булдырылган популяция селекциясе механизмнары хатын-кызларны бала табуга сәләтсез кыла, әмма ир-атларны җенси яктан “сарыф итүче” хатын-кызларны бракка чыгара.

Ир-атларда - “сыра кораклары”, ә хатын-кызларда билнең булмавы ир-атларда сексуаль уңышсызлыкка таруның стрессоген билгеләре булып санала. Бу - гәүдәнең эротик булмавын арттыра. Медицина статистикасы тарафыннан миокард инфаркты булу ихтималы белән билнең юанлыгы арасында турыдан-туры бәйләнеш барлыгы исбатланган. Күрәсең, шәхеснең үз кавемен, сексуаль арттыруда катнашмавы торган саен аның эротик яктан җәлеп итүчәнлеген киметә бара һәм соңыннан аны ырудан “бөтендәй сызып ташлый”.

Шәрәлекне һәм эротизмны гадәткә керткән, җәелдергән халыклар, этнослар (борынгы греклар, римлылар һ.б.) юкка чыккан, бары тик исемен һәм өлешчә телен саклап калган башка халыклар белән алыштырылган. Антик чор грекларын һәм римлыларны колачлап алган сексуаль азгынлык, ялангач тән культы, мөгаен, аларның бетү сәбәпләрнең берсе булгандыр. Хәзер әлеге катлаулар тарих картасыннан юк ителгән. Әле шунысы бар: алар сугыш хәрәкәтләре аркасында түгел, ә эчтән җимерелгәннәр. Ә инде Содом һәм Гоморра шәһәрләрендә яшәүчеләр хакында Инҗилдә һәм Коръәндә язылганнар - күпсанлы мисалларның берсе. Алар табигать законнарын бозып һәм аның табигый механизмнарын җимереп, үз-үзләрен юкка чыгару юлыннан киткәннәр.

Әмма үзләренең борынгы бабаларының традицион кыйммәтләрен саклаучы халыклар да әле яши. Барыннан да элек, болар - мөселман халыклары, әмма үз вакытында хәзерге славяннарның да нәсел-ыруы нәкъ шундый булган. Россиядәге барлык халыкларда да әле XIX гасырда да хатын-кызларның киеме гәүдәне иркен итеп капларлык, озын итәкле күлмәкләрдән, сарафаннардан һ.б. торган. Әлеге кием ачык төстә, бәйрәмчә, күптөрле төсле (күп очракта кызыл төс өстенлек иткән) булган. Алар, хатын-кызларны матурайтып, үзләренә ир-атларны караттырган, әмма эротик хисләр уяттырмыйча, берничек тә гәүдәгә сыланмыйча һәм һич кенә дә хатын-кыз күкрәген ассызыкламыйча. “Абайламый калу, махы бирү” дигән борынгы рус гыйбарәсен искә төшерик, ягъни уйламаганда гына яулык салу, чәчне чыгару - бу инде “ялгышлык җибәрүне”, ахмаклык эшләүне аңлаткан һәм аны тиз генә төзәтергә кирәк булган”. Борынгы рус фрескаларына (штукатурка өстенә төшерелгән бизәкләр), иконаларга һәм кульъязмаларга, узган гасыр ханымнарының портретларына, крестьян хатын-кыз образларына игътибар итик - әхлакый сафлык бөркелеп торган матур хатын-кыз кием культурасын күребез. Дини традицияләргә таянган барлык халыкларда да кием-салым культурасы шундый булган. Үз хатын-кызларның гыйффәтлеген, әхлакый йөзен саклап, җәмгыять бер үк вакытта үз ир-атларның да сәламәтлеген саклаган.

Хәзер матурлык белән сәламәтлек арасындагы кулай нисбәтне кайтару, кием-салымның нәрсәгә кирәклеген дөрес аңлау өчен моданы чак кына артка, традицион формаларга кайтарту кирәк. Шул чакта барысы да гадәттәгечә, без теләгәнчә булачак, дип раслый галимнәр.

**(www.psyfactor.org сайты мәгълүматлары файдаланылды).**

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Шәүүәл-Зөлҡағиҙә 2013 миләди йыл**
**1434 һижри йыл.**

| Шәүүәл, Зөлҡағиҙә | Аҙна көндәре | Июнь, Июль | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Йома | 16 | 5.25 | 6.55 | 14.30 | 20.14 | 21.44 | 23.14 |
| 10 | Шәмбе | 17 | 5.27 | 6.57 | 14.30 | 20.12 | 21.42 | 23.12 |
| 11 | Йәкшәмбе | 18 | 5.29 | 6.59 | 14.30 | 20.10 | 21.40 | 23.10 |
| 12 | Дүшәмбе | 19 | 5.30 | 7.00 | 14.30 | 20.07 | 21.37 | 23.07 |
| 13 | Шишәмбе | 20 | 5.32 | 7.02 | 14.30 | 20.05 | 21.35 | 23.05 |
| 14 | Шаршамбы | 21 | 5.34 | 7.04 | 14.30 | 20.03 | 21.33 | 23.03 |
| 15 | Кесе йома | 22 | 5.36 | 7.06 | 14.30 | 20.00 | 21.30 | 23.00 |
| 16 | Йома | 23 | 5.38 | 7.08 | 14.30 | 19.58 | 21.28 | 22.58 |
| 17 | Шәмбе | 24 | 5.40 | 7.10 | 14.30 | 19.56 | 21.26 | 22.56 |
| 18 | Йәкшәмбе | 25 | 5.41 | 7.11 | 14.30 | 19.53 | 21.23 | 22.53 |
| 19 | Дүшәмбе | 26 | 5.43 | 7.13 | 14.30 | 19.51 | 21.21 | 22.51 |
| 20 | Шишәмбе | 27 | 5.45 | 7.15 | 14.30 | 19.48 | 21.18 | 22.48 |
| 21 | Шаршамбы | 28 | 5.47 | 7.17 | 14.30 | 19.46 | 21.16 | 22.46 |
| 22 | Кесе йома | 29 | 5.49 | 7.19 | 14.30 | 19.43 | 21.13 | 22.43 |
| 23 | Йома | 30 | 5.51 | 7.21 | 14.30 | 19.41 | 21.11 | 22.41 |
| 24 | Шәмбе | 31 | 5.52 | 7.22 | 14.30 | 19.39 | 21.09 | 22.39 |
| 25 | Йәкшәмбе | 1 | 5.54 | 7.24 | 14.30 | 19.36 | 21.06 | 22.36 |
| 26 | Дүшәмбе | 2 | 5.56 | 7.26 | 14.30 | 19.34 | 21.04 | 22.34 |
| 27 | Шишәмбе | 3 | 5.58 | 7.28 | 14.30 | 19.31 | 21.01 | 22.31 |
| 28 | Шаршамбы | 4 | 6.00 | 7.30 | 14.30 | 19.29 | 20.59 | 22.29 |
| 29 | Кесе йома | 5 | 6.02 | 7.32 | 14.30 | 19.26 | 20.56 | 22.26 |
| 30 | Йома | 6 | 6.04 | 7.34 | 14.30 | 19.24 | 20.54 | 22.24 |
| 1 | Шәмбе | 7 | 6.05 | 7.35 | 14.30 | 19.21 | 20.51 | 22.21 |
| 2 | Йәкшәмбе | 8 | 6.07 | 7.37 | 14.30 | 19.19 | 20.49 | 22.19 |
| 3 | Дүшәмбе | 9 | 6.09 | 7.39 | 14.30 | 19.16 | 20.46 | 22.16 |
| 4 | Шишәмбе | 10 | 6.11 | 7.41 | 14.30 | 19.14 | 20.44 | 22.14 |
| 5 | Шаршамбы | 11 | 6.13 | 7.43 | 14.30 | 19.11 | 20.41 | 22.11 |
| 6 | Кесе йома | 12 | 6.15 | 7.45 | 14.30 | 19.08 | 20.38 | 22.08 |
| 7 | Йома | 13 | 6.16 | 7.46 | 14.30 | 19.06 | 20.36 | 22.06 |
| 8 | Шәмбе | 14 | 6.18 | 7.48 | 14.30 | 19.03 | 20.33 | 22.03 |
| 9 | Йәкшәмбе | 15 | 6.20 | 7.50 | 14.30 | 19.01 | 20.31 | 22.01 |

# ХӘЕРЕҢ БЕЛӘН, ШӘҮВӘЛ АЕ

Рамил хәзрәт МИҢГӘРӘЕВ

Һижри календарьда изге Рамазан аен шәүвәл ае алыштыра. Буй айның беренче көнендә без Ураза бәйрәмен билгеләп үттек...

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) әйткән: “Рамазан уразасынан соң шәүвәл аенда алты көн ураза тотучыга тулы ел дәвамында ураза тоткан кебек савап булыр, чөнки безнең шәригатебездә бер изгелеккә ун өлеш саваптан ким булмас. Исәпләсәк утыз көнгә өч йөз, алты көнгә алтмыш көн ураза булыр”. Дәхи Рәсүлуллаһ әйтә: “Бер кеше Рамазаннан соң шәүвәл аенда алты көн ураза тотса,Аллаһы Тәгалә бу кешенең тәнен тәмугка хәрам кылыр. Һәр көне бәрабәренә кырык шәһид (сугышта шәһид булган сәхабәләр) савабын бирер, һәр көне бәрабәренә бу кеше өч оҗмахта бер шәһәр бина кылырлар”.

Без Сезгә бу шәүвәл ае хакында, аның кодрәте, бу айда кыла торган гыйбадәтләр хакында бераз аңлатып үтәбез.

1890 елда Санкт-Петербургта басылып чыккан “хуләсәтүлмәсәилә үә мүһимматүл-дәләил” китабының туксан алтынчы битендә шәүвәл ае тарихы язылa.

Башка айлар кебек үк бу айның да исеме гарәп падишаһларының исеме белән бәйле. Бәни Гайсә кабиләсенең Әнүш исемле падишаһы була. Ул гомеренең күбрәк өлешен сахраларда урманнарды йөрөп, төрле бөҗәкләрне, аларның тән төзелешен өйрәнеп уздыра торган була. Һәрбер хакимдә була торган үзенә бертөрле сәерлек Әнүш падишаһта да була. Ул гомере буе диңгеҙ буенда яшәргә тиешле кигәвен зурлыгындагы яшел чебен эзли... Көннәрдән беркөнне, кояш баегач, диңгез буенда нәкь шул чебеннәрнең өерен күрә һәм гаҗәпләнеп кычкырып җибәрә: “Мә һәзәл шәүвәләте”, ягъни “Бу нинди ачыш!” мәгънәсендә. Бу - ул вкытта “туван” дип аталган айның ахыргы көне була һәм Әнүш падишаһ бу айны шушы ачыш хөрмәтенә “шәүвәл” дип атый. Ислам дине кергәнче, шәүвәлнең беренче көне гарәпләрдә нәхес, ягъни бәхетсезлек, шомлылык, уңышсызлык көне дип исәпләнелгән.

Гарәп ярымутравына ислам дине кергәч, шәүвәлнең беренче көне Гайдел-фитыр көне, ягъни Рамазан уразасы тәмам булганнан соң бәйрәм ителә торган Ураза гаете булды. Без хәзер шушы изге айга керештек. Рәсүлебез (с.г.в.) бик күп хәдисләрдә шушы айның фазыйләтләре хакында безгә аңлатты. Өммәтебезгә нәсыйхәт кылып, Рамазан аенда яшәгән гомеребезнең, кадерле тормышыбызның тагын дә дәвамы булсын өчен, гамәлләребез тагын да ихлас булсын өчен, шушы шәүвәл аенда өстебезгә тагын бер гыйбадәтне йөкләде. Барча мөселман өммәтен дә Рамазан аенда тоткан ураза кебек, шулай ук шәүвәл аенда да алты көн ураза тотып уздырырга тиешле. Бу, әлбәттә, өстебезгә йөкләтелгән фарыз, вәҗәб гыйбадәт ук булмаса да, мәгәр безнең иманыбызның Рамазан аенда пакьләнүе, җаныбызның, тәнебезнең сафлануы тагын да дәвам итү өчен зур мөмкинчелек бу. Хәтта рәсүлебез (с.г.в.) бер хәдисендә: “Шәүвәл аенда алты көн тоткан уразасына кеше дөньяга килгән сабый бала кебек гөнаһсыз булыр”, - диде. Иң мөһиме: ихлас булып, шушы гыйбадәтне башкарып та без мактaлырга тиешбез. Ягъни Рамазан аенда Әлхәмдүлилләһ, барчаларыбыз да бер ай гомеребезне ризыктан, эчемлектән, гөнаһлы гамәлдән тыелып уздырдык. Шушы гамәлебез дәвамлы булсын өчен без бу гыйбадәткә дә көч-куәтебезне куярга тиешлебез. Нәфел гыйбадәт кенә булса да, рәсүлебез (с.г.в.) аны һәрвакыт үтәде (ягъни моны сөннәт мүәккәдә дип алырга кирәк). Шундый сөенеч бирелгән шәүвәл аенда. Аллаһ Раббыбыз шушы мөбарәк шәүвәл айларыбызда да уразагыйбадәтләребезне башкарып, барчыбызга да бу йөкләтелгән бурычны үтәргә ярдәм итсә иде. Аллаһ Раббыбызның кодрәте белән Рамазан аенда да ураза гыйбадәтен башкардык, шәүвәл аенда да шушыны дәвам итеп, шатлыксөенеч белән шәүвәл уразаларын тотарга да барчабызга Аллаһы тәгалә үзе насыйп әйләсә иде. Әмин!